Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №II-3**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 14 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының даими комиссияләрен төзү турында» ел, №I-4 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 мартындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 32 статьялары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Совет Регламентының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының даими комиссияләрен төзү турында» 23.09.2025 ел, №I-4 карарына, карарның 1 пунктын кушымтада бирелгән редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының түбәндәге даими комиссияләрен төзергә:

- бюджет, финанс, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча 11 депутаттан торган даими комиссия;
-транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча 10 депутаттан торган даими комиссия;
- социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча 10 депутаттан торган даими комиссия;
- экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча10 депутаттан торган даими комиссия;
- законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча 11 депутаттан торган даими комиссия».

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башлыгы — Р.Р. Ислямов